# «Бөтен дөньяның экологик проблемалары» темасы буенча фәнни конференция

# Максат:

- Экологик проблеманың актуальлеген исбатлау.
- Әйләнә-тирә мохитне төп пычрану чыганакларын ачыклау.
- Әйләнә-тирә мохитне пычрату проблемаларын чишү.

- Экология - тере һәм тере булмаган организмнарның үзара бәйләнешен өйрәнә торган фән (экос – йорт, логос – фән).
- Табигать – кешенең яшәү тирәлеге, аның төрле ихтияҗларын канәгатьләндерүче төп һәм еш кына бердәнбер чыганак.

Кеше үзен чолгап алган мохиткә җайлашып кына калмый, ә бәлки аны үзгәртә дә. Табигатьнең барлык компонентлары үзара тыгыз бәйләнештә тора, аларның берсен үзгәртү калганнарында үзен сиздерә. Шуңа күрә табигатьне үзгәрткәндә аның нәтиҗәсе нинди булачагын кеше алдан күрә белергә һәм, кирәк икән аларны булдырмый калырга тиеш.

Бу гасырның иң мөхим экологик проблемаларның берсе булып сулар пычрану тора. Елга һәм күл суларының артык пычрануы кеше сәламәтлегенә, бигрәк тә халык тыгыз утырган районнарда, тәэсир итми кала алмый.

Һаваны пычратучы төп чыганаклар – промышленность предприятиеләре, алар ел саен атмосферага гаятькүп күләмдә зарарлы матдәләр чыгара, ә алар үз чиратында кислоталы яңгырлар булып ява (Красноярск, Ангарск, Уралда).

Мәскәү һәм Санкт-Петербург өстендә даими рәвештә төтен – смог тора.

АЭС ндәге аварияләр аянычлы экологик нәтиҗәләр белән аерылып тора. Чернобыль - Россиянең Европа өлешенә генә түгел, күрше илләргә дә барып иреште.

Шулай итеп, кеше үзенең хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә табигатькә, шуның белән беррәттән үзенең сәламәтлегенә дә зур зыян китерә.

**Табигатькә карата кешенең тискәре эшчәнлеге үзара бәйләнеше 3 формада бирелә:**

1) Әйләнә-тирә мөхитне пычрату.
2) Табигый ресурс чыганакларының кимүе.
3) Табигатьнең җимерелүе.

# Табигатьнең пычрануына берничә мисал:









| ПЫЧРАНУНЫҢ ТӨП ТИПЛАРЫ | | | |
|---|---|---|---|
| Физик (җылылык, тавыш, электромагнит, яктылык, радиоактив) | Химик (авыр металлар, пестицидлар, пластмассалар һәм химик матдәләр) | Биологик (биоген, микробиологик, генетик) | Информацион (информацион тавыш) |

# Җирнең атмосферасы, гидросферасы и литосферасы пычранутга дучар була.



# Табигатьнең пычрануы


| | Пычрануның төп чыгынаклары | Төп агулы матдәләр |
|---|---|---|
| Атмосфера | Промышленность<br>Транспорт<br>Җылылык электростанцияләре | Углерод оксиды, күкерт, азот<br>Органик кушылмалар<br>Промышленность тузаны. |
| Гидросфера | Агым сулар<br>Нефтьнең агып чыгуы<br>Автотранспорт | Авыр металлар<br>Нефть<br>Нефть продуктлары |
| Литосфера | Авыл хуҗалыгы һәм промышленность калдыклары<br>Ашламаларны кирәгеннән артык куллану | Пластмасса<br>Резин<br>Авыр металлар |

# Табигатьтән рациональ файдалану

Кеше һава, су, туфрак, файдалы казылмалар һәм башка шундый күп төрле табигый байлыклардан файдаланып, һәрвакытта да аларны тиешенчә һәм сакчыл кулланмый.

Табигатьтән рациональ файдалану – ул җәмгыятьнең көннән - көн үсә барган ихтыяҗларын тәэмин итүдә табигый ресурслардан файдалануны төрле яклап интенсивлаштыру, табигый байлыкларны киләчәк буыннар өчен саклап калдыру, кешеләрнең сәламәтлеген саклау, табигый комплексларның эстетик үзенчәлекләрен кире үз хәленә кайтару һәм аларны саклау юлларын үз эченә алган максатчан эшчәнлек.

# Табигатьне саклау




- ул җәмгыять мәнфәгатьләрендә табигатьне саклауга һәм күзәтү астында үзгәртүгә юнәлтелгән икътисади, фәнни, админстратив – хокукый чараларның тулы бер комплексы.

# Табигатьне саклау чаралары:

- Зарарлы матдәләрне чистарту (фильтрлау)
- Чистарту корылмалары куллану
- Пычратуны киметү өчен аз калдыклы һәм перспективада калдыксыз технологияле производстволар куллану
- Уку йортларында табигатьне хөрмәтләү буенча экологик тәрбия кертү.

**Без үзебез генә нәрсә эшли алабыз, барыбыз бергә нишли алабыз?**

- Табигый ресурсларны акыл белән, экономияле, калдыксыз куллану.

Суны



утны



Җылылыкны




ягулыкны



Безнең бурыч – Җир-ананың табигый байлыкларын саклап калу һәм тагын да арттыру.

# Видеоролик



Хәзерге заманда актуаль булган экологик проблемаларны чагылдыручы сораулар

Туган як табигатен саклауда сез нинди эшләр башкара аласыз?

## Хәзерге заманда актуаль булган экологик проблемаларны чагылдыручы сораулар

Безнең дөньяда сулыклар болай да күп, сулыкларны саклау кирәкме?

## Хәзерге заманда актуаль булган экологик проблемаларны чагылдыручы сораулар

Һава чисталыгын нинди юллар белән сакларга була?

## Хәзерге заманда актуаль булган экологик проблемаларны чагылдыручы сораулар

# Промышленность һәм кешенең хуҗалык эшчәнлегенең башка объектларыннан чыккан экологик зыяннар?

Хәзерге заманда актуаль булган экологик проблемаларны чагылдыручы сораулар

Урман һәм торф янгыннары белән ничек көрәшергә була?

Хәзерге заманда актуаль булган экологик проблемаларны чагылдыручы сораулар

Сез энергия чыганакларының нинди экологик чиста төрләрен беләсез?


Игътибарыгыз өчен
рәхмәт!